Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Рус Әшнәге авыл җирлеге Советы

**КАРАР № 10**

Рус Әшнәге авылы 2019 елның 8 июле

Законнардагы һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының үзидарәлек норматив хокукый актларындагы үзгәрешләр мониторингын үткәрү турында Нигезләмәне раслау хакында

Законнардагы һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлеге җирле үзидарә органнары тарафыннан кабул ителгән үзидарәлек норматив хокукый актларындагы үзгәрешләр мониторингын үткәрү буенча Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлеге җирле үзидарә органнары эшен камилләштерү максатларында, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "Рус Әшнәге авыл җирлеге" үзидарәлек берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Законнардагы һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының үзидарәлек норматив хокукый актларындагы үзгәрешләр мониторингын үткәрү турында кушымта итеп бирелә торган Нигезләмәне расларга.

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлеге җирле үзидарә органнарына:

үзләренең нормалар иҗат итү (эшләү) эшчәнлегендә әлеге карарның 1 пункты белән расланган Нигезләмәгә таянырга;

күрсәтелгән Нигезләмәне үтәү өчен җаваплы затлар билгеләргә;

җаваплы затлар итеп билгеләнгән үзидарәлек хезмәткәрләренең вазыйфаи инструкцияләренә (күрсәтнамәләренә) тиешле үзгәрешләрне кертергә.

3. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлегенең түбәндәге адрес буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Рус Әшнәге авылы,Мәктәп урамы, 7А йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"ында урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән соң ун көн узгач үз көченә

керә.

5. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Рус Әшнәге авыл җирлеге башлыгы В.Һ.Хаҗиев

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Рус Әшнәге авыл җирлеге Советының
2019 елның 8 июлендәге 10 номерлы
карары белән расланды

**Законнардагы һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының үзидарәлек норматив хокукый актларындагы үзгәрешләр мониторингын үткәрү турында Нигезләмә**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлеге җирле үзидарә органнары тарафыннан кабул ителгән үзидарәлек норматив хокукый актларының хокук куллану мониторингын гамәлгә ашыру тәртибен тәгаенли (алга таба – норматив хокукый актлар мониторингы).

2. Законнардагы һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының үзидарәлек норматив хокукый актларындагы үзгәрешләр мониторингы җирле үзидарә органнары тарафыннан үзләренең вәкаләтләре чикләрендә гамәлгә ашырылучы үзидарәлек актларын кабул итү (бастырып чыгару), үзгәртү яисә көчен югалтуын тануны (гамәлдән чыгаруны) тәэмин итү өчен мәгълүмат җыйнау, гомумиләштерү, анализлау һәм бәяләү буенча системалы, комплекслы һәм планлы эшчәнлекне күз алдында тота.

3. Мониторинг Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлеге җирле үзидарә органнары тарафыннан үткәрелә.

4. Җирле үзидарә органнары мониторинг үткәргәндә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы аппаратының юридик бүлеге һәм үзидарәлек берәмлегенең башка җирле үзидарә органнары белән элемтәдә торып хезмәттәшлек итәләр.

5. Мониторинг үткәрү өчен Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында җаваплы затлар билгеләнә.

6. Мониторинг үткәрүнең максатлары булып тора:

федераль һәм республика законнарына яраклаштыру максатларында үзидарәлек актларын кабул итүдә, үзгәртүдә һәм көчен югалтуын тануда ихтыяҗны ачыклау;

үзидарәлек актларындагы коллизияләрне, каршылыклар һәм кимчелекләрне,

хокукый җайга салуда кабатлауларны бетерү;

җирле үзидарә органнарының норматив хокукый базасын системалаштыруны тәэмин итү:

үзидарәлек актларындагы коррупциягә (ришвәтчелеккә) җирлек тудыручы факторларны ачыклау;

кирәк булмаган (актуальлеген югалткан) яки практикада кулланылмаучы үзидарәлек актларын яисә аларның аерым нигезләмәләрен (нормаларын) ачыклау;

хокук куллануның нәтиҗәлелеген күтәрү, үзидарәлек актларын тормышка ашыруның нәтиҗәлелеген төшерүче факторларны ачып бирү;

җирле үзидарә органнарының тиңдәшле бүлекчәләре тарафыннан үзидарәлек актларының үтәлүенә контрольне гамәлгә ашыруга булышлык итү;

нормалар эшләү (иҗат итү) процессын камилләштерү буенча тәкъдимнәр эшләү.

6. Мониторинг үзгәрешләрне җыйнауны, гомумиләштерү, анализлау һәм бәяләүне үз эченә ала:

Россия Федерациясенең конституциячел законнары, федераль законнары һәм бүтән закон актларындагы;

Россия Федерациясе Президенты указлары, Россия Федерациясе Хөкүмәте карарлары, башкарма хакимиятнең федераль органнары норматив хокукый актлары, федераль дәрәҗәдәге законнарга ярдәмче бүтән норматив хокукый актлардагы;

Татарстан Республикасы законнары һәм бүтән норматив хокукый актларындагы;

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлеге Уставындагы, үзидарәлек актларындагы.

8. Мониторингны үткәрүгә нигез булып тора:

федераль һәм республика закон актларына үзгәрешләр кертү;

хокукый җайга салуның билгеле бер өлкәсендә үзидарәлек актларын куллануга анализ;

прокуратура органнары хәбәре (мәгълүматы);

гаммәви мәгълүмат чараларының үзидарәлек актларының җитешсезлекләре яки аларны камилләштерү зарурлыгы турында хәбәре;

гражданнарның, юридик затлар, шул исәптән җәмәгать, фәнни, хокук яклау һәм бүтән оешмаларның, индивидуаль эшмәкәрләрнең, дәүләт хакимияте органнарының, муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары депутатларының үзидарәлек актларының камил булмавы хакында мөрәҗәгатьләре, шул исәптән үз эченә алган:

Татарстан Республикасы үзидарәлек норматив хокукый актлар регистрына кертелгән үзидарәлек актларына карата Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы тарафыннан үткәрелгән хокукый экспертиза бәяләмәсен;

аларны үткәрүгә вәкаләтле затларның үзидарәлек актларына тиешле тәртиптә әзерләнгән коррупциягә каршы экспертиза бәяләмәләрен;

җирле үзидарә органнары тарафыннан үткәрелүче конференцияләр, семинарлар, халык тыңлаулары, җәмәгатьчелек фикер алышулары һәм башка чараларның йомгаклау документларын.

## II. Мониторингны үткәрү тәртибе

9. Җирле үзидарә органнары мониторингны үзләренең компетенциясендәге мәсьәләләр буенча әлеге Нигезләмәнең 5 пунктында күрсәтелгән җаваплы затлар белән үзара элемтәдә (хезмәттәшлектә) үткәрәләр.

Мониторингны үткәрү максатларында эшче төркемнәр төзелергә, киңәшмәләр, консультацияләр үткәрелергә, кирәкле мәгълүматны соратып алдырырга, Татарстан Республикасы, Россия Федерациясе субъектларының бүтән муниципаль берәмлекләре тәҗрибәсе өйрәнелергә, бүтән эш формалары файдаланылырга мөмкин.

10. Мониторинг анализ ярдәмендә гамәлгә ашырыла:

әлеге Нигезләмәнең 6 пунктында күрсәтелгән актларга;

федераль, республика һәм муниципаль дәрәҗәдәге норматив хокукый актларга дәгъва белдерү турындагы эшләр буенча хөкем актларына (хөкем гамәленә);

прокурор илтифат итүе (реакциясе) актларына.

11. Мониторингны үткәрү формалары:

1)тармак мониторингы – эшчәнлекнең билгеле бер өлкәсендә норматив хокукый актларны куллану турында мәгълүмат алу өчен гамәлгә ашырылучы мониторинг;

2)нокталы (урынлы) мониторинг – конкрет норматив хокукый актны яисә аның бер өлешен куллану турында мәгълүмат алу өчен гамәлгә ашырылучы мониторинг;

3) оператив мониторинг – норматив хокукый актларның гамәлдә булуларының беренче елы дәвамында кулланылулары турында мәгълүмат алу өчен гамәлгә ашырылучы мориторинг.

12. Мониторингны, җирле үзидарә органнарының норматив базасын анализлауны, шулай ук мониторинг йомгаклары буенча үткәрелүче нормалар булдыру эшенең нәтиҗәләрен беркетүне (билгеләүне) гамәлгә ашыру максатларында үзидарәлек норматив хокукый актлар реестрлары файдаланыла, алар җирле үзидарә органнарында үзидарәлек норматив хокукый актлары реестрын оештыру һәм алып бару тәртибе турында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы карары нигезендә алып барылалар.

13. Мониторингны гамәлгә ашыру процессын оптимальләштерү өчен мәгълүмати системаларның автоматлаштырылган сервислары файдаланыла (аларның операторлары белән контрактлар, килешүләр төзү белән бәйле күрсәтелгән мөмкинлек булганда), алар тәэмин итә:

“Консультант плюс” мәгълүмати системасында контрольгә куелган закон һәм бүтән норматив хокукый актлардагы үзгәрешләр турында мәгълүматның керүен;

“Консультант плюс” мәгълүмати системасының хокукый җайга салуның тиңдәшле өлкәләре буенча яңалыклар ленталарының мәгълүматы керүен;

Үзидарәлек актларының законнарга ачыкланган туры килмәүләре турында “Кодекс” мәгълүмат компаниясенең “Төбәк законнары аналитигы” автоматлаштырылган мәгълүмати системасының мәгълүматы керүен.

Мониторингны гамәлгә ашыру процессын оптимальләштерү максатларында бүтән мәгълүмати системалар сервислары файдаланылырга мөмкин.

14. Әлеге Нигезләмәнең 10 пунктында күрсәтелгән анализ белән беррәттән үзидарәлек хокукый актларын кабул итүне (бастырып чыгаруны), үзгәртү яисә көчен югалтуын тануны (гамәлдән чыгаруны) тәэмин итү өчен мониторингны гамәлгә ашырганда үзидарәлек актларын куллану практикасы турындагы мәгълүмат түбәндәге критерийлар буенча гомумиләштерелә һәм бәяләнә:

кеше һәм гражданның гарантияләнгән хокукларын, ирек һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү;

үзидарәлек актларын кабул итү (бастырып чыгару) зарурлыгы тәгаенләнгән күбрәк юридик көчкә ия норматив хокукый актларның булуы;

муниципаль актны бастырып чыгарганда җирле үзидарә органы компетенциясе чикләрен үтәү;

үзидарәлек актында коррупциячел факторларның булуы;

хокукый җайга салуда иҗтимагый мөнәсәбәтләрнең тулылыгы;

хокук нормалары коллизиясе;

юридик-техник характердагы хаталарның булуы;

үзидарәлек актын кулланганда аның нигезләмәләренең мәгънәсен бозу;

үзидарәлек хокукый актын кулланганда урынсыз яки нигезсез карарлар, гамәлләр (гамәл кылмаулар);

норматив хокукый актларны куллану практикасының булуы;

норматив хокукый актларны бертөрле куллану практикасының юклыгы;

үзидарәлек актын аңлату мәсьәләләре буенча гаризаларның булуы (саны) һәм эчтәлеге;

мөрәҗәгать итүчеләрнең (гариза бирүчеләрнең) үзидарәлек акты тарафыннан җайга салынган мөнәсәбәтләр белән бәйле таләпләрен канәгатьләндерү (канәгатьләндерүне кире кагу) турында закон көченә кергән хөкем актларының булуы (саны) һәм аларны кабул итүнең нигезләре.

15. Мониторинг нәтиҗәләре буенча федераль һәм республика законнарының муниципаль актлар үзгәрешләрен китереп чыгаручы үзгәрүләре беленгән очракта җирле үзидарә органнары тарафыннан:

үзидарәлек актына үзгәрешләр кертү, үзидарәлек актының көчен югалтуын тану, яңа үзидарәлек акты кабул итү турында үзидарәлек актларының тиңдәшле проектлары эшләнә;

үзидарәлек актларын күбрәк юридик көчкә ия актлар белән тәңгәллеккә китерүгә юнәлтелгән бүтән төрле чаралар күрелә.

16. Федераль һәм республика законнарына муниципаль актларга үзгәрешләр кертү зарурлыгын китереп чыгара торган үзгәртүләр керткән очракта мониторинг федераль яки республика актын бастырып чыгарган мизгелдән соң 30 көн дәвамында үткәрелә.

Мониторинг үткәрүгә гражданнарның, юридик затлар, индивидуаль эшмәкәрләрнең, дәүләт хакимияте органнарының, муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары депутатларының мөрәҗәгатьләре, шулай ук прокуратура мәгълүматы (хәбәре), “Россия Федерациясе прокуратурасы турында” федераль законда билгеләнгән срокларда каралучы прокурор илтифаты актларыннан гайре, нигез булган очракта мониторинг алар кергән көннән соң 30 көн дәвамында гамәлгә ашырыла. Күрсәтелгән очракларда мониторингны үткәрү нәтиҗәләре

хакында мөрәҗәгать иткән затка хәбәр ителә.

Ерак перспективада көченә керүче федераль һәм республика закон актларының үзгәрешләре ачыкланган очракта җирле үзидарә органнарының норма булдыру эшчәнлеге планнарына тиңдәшле төзәтмәләр турында тәкъдимнәр кертелә.

## III. Мониторинг нәтиҗәләрен тормышка ашыру

17. Мониторинг нәтиҗәләре буенча үзидарәлек акты проектын эшләү һәм кабул итү тиңдәшле федераль һәм (яки) республика актын, әлеге Нигезләмәнең 16 пунктының өченче абзацында күрсәтелгән очрактан гайре, үзгәртү вакытыннан соң ике айдан да артык булмаган срокта үткәрелә.

18. Мониторингны үткәрүгә җаваплы затлар ай саен хисап аеннан соң килүче айның 5 нче числосыннан да соңармыйча җирле үзидарә органнары җитәкчеләре алдында мониторинг нәтиҗәләре турында хисап тоталар.

18.1. Мониторинг нәтиҗәләре турында хисап (мәгълүматлар) үз эченә алырга тиеш:

мониторинг үткәрү объекты турында мәгълүматны;

мониторинг үткәрүне башкаручылар турында мәгълүматны;

мониторинг үткәрү периоды (чоры) турында мәгълүматны;

хокукый җайга салу предметына, мониторингны үткәрү нигезенә кыскача характеристиканы.

18.2. Мониторинг нәтиҗәләре турында хисап (мәгълүматлар) үз эченә алырга мөмкин:

хокукый җайга салуның ачыкланган проблемалары турында мәгълүматны;

үзидарәлек актларына үзгәрешләр кертү буенча һәм (яки) яңаларын кабул итүнең зарурлыгы, үзидарәлек актларын гамәлдән чыгару турында рекомендацияләрне (тәкъдимнәрне);

хокук мөнәсәбәтләренең тиңдәшле өлкәсендә хокукый җайга салуны камилләштерүгә юнәлтелгән мониторинг йомгакларына нигезләнгән бүтән нәтиҗәләр һәм тәкъдимнәрне.

19. Мониторинг нәтиҗәләре буенча яңа кабул ителгән үзидарәлек актлары законнар белән билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда Татарстан Республикасы үзидарәлек норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрелә.

Күрсәтелгән регистрга кертү өчен анда булмаган мониторинг нәтиҗәләре буенча ачыкланган үзидарәлек актлары җибәрелә.

20. Мониторинг нәтиҗәләре буенча нормалар булдыру процессын камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерләнергә мөмкин.

## IV. Җаваплылык

21. Мониторингны үткәрүгә һәм хокуклар булдыру эшчәнлеге өчен җаваплы затлар мониторингны оештыру өчен, шулай ук җирле үзидарә органнары карамагындагы хокукый җайга салуның тиңдәшле өлкәсендә үзидарәлек актларын федераль һәм республика законнарына үзвакытында яраклаштыру өчен персональ (шул исәптән дисциплинар тәртиптә) җаваплы булалар.

22.Мониторинг йомгаклары буенча тискәре нәтиҗәләргә, шул исәптән гражданнарга, юридик затларга, җәмгыятькә һәм дәүләткә зыян китергән гамәлләр (гамәл кылмаулар) өчен законнар нигезендә җирле үзидарә органнары җитәкчеләре җаваплы була.